КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 26 ноябрь г.Казань № 1052

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы мәсьәләләре» 2004 ел, 30 декабрь, 614 нче карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы мәсьәләләре» 2004 ел, 30 декабрь, 614 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 ел, 15 апрель, 187 нче; 2006 ел, 2 август, 396 нчы; 2007 ел, 12 октябрь, 549 нчы; 2009 ел, 2 март, 117 нче; 2009 ел, 21 сентябрь, 657 нче; 2010 ел, 10 декабрь, 1036 нчы; 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2011 ел, 1 июль, 534 нче; 2011 ел, 25 октябрь, 887 нче; 2013 ел, 18 март, 178 нче; 2013 ел, 7 ноябрь, 858 нче; 2014 ел, 7 февраль, 70 нче; 2014 ел, 20 май, 336 нчы; 2014 ел, 10 декабрь, 970 нче; 2015 ел, 5 июнь, 422 нче; 2015 ел, 9 декабрь, 929 нчы; 2016 ел, 15 апрель, 227 нче; 2016 ел, 14 июль, 480 нче; 2016 ел, 27 июль, 517 нче; 2017 ел, 24 октябрь, 805 нче; 2018 ел, 4 июль, 552 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 нче пунктның икенче абзацында «вазыйфасы буенча Татарстан Республикасының гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министры булып тора» сүзләрен «тапшырылган вәкаләтләр кысаларында Татарстан Республикасының Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы һәм аның ведомство буйсынуындагы дәүләт учреждениеләре эшчәнлеген яраштыруны гамәлгә ашыра» сүзләренә алыштырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы турындагы нигезләмәдә:

1.3 нче пунктның икенче абзацында «бюджет» сүзен «дәүләт» сүзенә алыштырырга;

1.5 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.5. Үз эшчәнлегендә министрлык Россия Федерациясе Конституциясенә, Россия Федерациясе законнарына, Татарстан Республикасы Конституциясенә, Татарстан Республикасы законнарына, шулай ук бу Нигезләмәгә таянып эш итә.»;

5.2 нче пункт үз көчен югалткан дип санарга;

5.3 нче пунктта «Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар салган зыяннарны бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча баш идарәсе башлыгы –» сүзләрен төшереп калдырырга;

5.5 нче пунктта «Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар салган зыяннарны бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча баш идарәсе башлыгы –», «, кагыйдә буларак,» сүзләрен төшереп калдырырга;

5.6 нчы пунктта «Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар салган зыяннарны бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча баш идарәсе башлыгы –» сүзләрен төшереп калдырырга;

5.7 пунктның өченче абзацын төшереп калдырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры — А.В.Песошин